КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 февраль г.Казань № 182

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 894 нче; 2017 ел, 30 декабрь, 1133 нче; 2019 ел, 16 февраль, 111 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 774 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 923 нче; 2020 ел, 14 апрель, 285 нче; 2020 ел, 30 июнь, 548 нче; 2020 ел, 16 июль, 600 нче; 2020 ел, 3 сентябрь, 779 нчы; 2021 ел, 15 февраль, 82 нче; 2021 ел, 5 май, 309 нчы; 2021 ел, 8 июнь, 442 нче; 2021 ел, 16 август, 731 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2021 ел, 22 ноябрь, 1109 нчы; 2022 ел, 3 февраль, 81 нче, 2022 ел, 18 май, 461 нче, 2022 ел, 29 сентябрь, 1047 нче, 2022 ел, 31 октябрь, 1159 нчы һәм 2022 ел, 20 декабрь, 1375 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1.1 пунктның таблицасындагы 15 пунктның 2 нче графасында «Суд карары» сүзләрен «Суд карары күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

3.1.2 пунктның таблицасындагы 2 пунктның 2.1 пунктчасындагы 2 нче графасында «суд карары» сүзләрен «суд карары күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.2 пунктның таблицасындагы 2 пунктның 2.1 пунктчасындагы 2 нче графасында «суд карары» сүзләрен «суд карары күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

6.3.5 пунктның җиденче абзацында «суд карары» сүзләрен «суд карары күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 5 нче кушымтаның «Социаль хезмәт күрсәтүләр исемлекләре, аларны социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә (балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләре) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә күрсәтү тасвирламалары һәм күләмнәре» таблицасында:

1.1 пунктның 1.1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="3">«1.1.1.</td><td rowspan="3">Торак урыннар мәйданнарын бирү</td><td>Зурлыклары һәм башка тормыш күрсәткечләре буенча торак мәйданы (бина торышы һәм уңайлылык) санитария-гигиена нормаларына туры килергә һәм клиентларның яшәү уңайлылыгын тәэмин итәргә тиеш.<br>Бер балага йокы бүлмәсенең мәйданы:</td><td></td><td></td><td rowspan="3">социаль хезмәт күрсәтү чоры»;</td></tr>
<tr><td>3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр</td><td>кв.м</td><td>2 (җиһаз һәм аның урнашуын исәпкә алмыйча)</td></tr>
<tr><td>8 яшь һәм өлкәнрәк</td><td>кв.м</td><td>4</td></tr>
</table>

4.1 пунктның 6 графасында «социаль хезмәт күрсәтү чоры» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү чорында бер айга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 7 нче кушымтада «Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында балалар интернат-йортларында, психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән социаль хезмәт күрсәтүләрне алучылар өчен 18 яшьтән

23 яшькә кадәрге физик җитешсезлекләре булган балалар өчен интернат-йортларда күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтүләрнең исемнәре, тасвирламалары, күрсәткечләре һәм нәтиҗәләрен бәяләү» таблицасына түбәндәге эчтәлекле 8 бүлек өстәргә:

| «8. Сроклы социаль хезмәтләр күрсәтү | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 8.1. | Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат-йортларында социаль хезмәт күрсәтүләр алучыларны медицина оешмаларына хастаханәгә салганда озату | Медицина оешмасында стационар дәвалануда торучы социаль хезмәт күрсәтүләрне (психиатрия ярдәмен һәм «фтизиатрия» профиле буенча медицина ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларыннан тыш) алучы артыннан карау | хезмәтләр | 3 | елга"; |

әлеге Тәртипкә 8 нче кушымтада «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат-йортларында, 18 яшьтән өлкәнрәк социаль хезмәтләр алучылар өчен физик җитешсезлекләре булган һәм паллиатив ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтүләр күрсәткечләрен, тасвирларын, күрсәткечләрен һәм нәтиҗәләрен бәяләү» таблицасына түбәндәге эчтәлекле 5 бүлек өстәргә:

| «5. Сроклы социаль хезмәтләр күрсәтү | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5.1. | Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат-йортларында социаль хезмәт күрсәтүләр алучыларны медицина оешмаларына хастаханәгә салганда озату | Медицина оешмасында стационар дәвалануда торучы социаль хезмәт күрсәтүләрне (психиатрия ярдәмен һәм «фтизиатрия» профиле буенча медицина ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларыннан тыш) алучы артыннан карау | хезмәтләр | 3 | елга». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин